**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская Крепость, 423104

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте авылы, 423104

тел./факс(84396) 2-36-54 email: Sheshm.Cmn2@tatar.ru

20 сентябрь 2019 ел № 141

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**Шешминка авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында.**

2002 елның 12 июнендәге 67 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында " 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Шешминка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Шешминка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 18 сентябрендә кабул ителгән 140 номерлы «Референдум үткәрү инициативасы турында» карарын карап тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 елның 17 ноябренә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Килешәсезме 2020 елда көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнар, 1 төркем инвалидлардан тыш Шешминка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча юнәлтү турында:

- Андреевка торак пунктында зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (койма урнаштыру, ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу(хезмәтләр күрсәтү));

- Шешминка крепосте торак пунктында суүткәргеч челтәрләренең проект һәм тикшерену эшләре (инженерлык эзләнүләр, проект эшләре,проект экспертизасы),

югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү));

- Шешминка крепосте, Андреевка, Павловка, Нагай торак пунктларында урам утларын ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

- Шешминка крепосте һәм Андреевка торак пунктларында юл челтәрен кышкы чорда карап тоту һәм җәйге чорда чабу, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү) .

ӘЙЕ ЮК»

3. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» - («Наш Черемшан») район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шешминка авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе М.Д. Шәйхетдинов